**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«24» 02 2026 ел Яр Чаллы ш. №449

«ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында» 2025 елның 10 ноябрендәге 3961 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетның 2025 елның 10 нояберендәге 3961 номерлы карары белән расланган ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов

Муниципаль район Башкарма комитетының 2026 елның «24» 02. 449 номерлы карарына 1 кушымта

2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Нульдән тегү» | 550,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры __________ З. А. Гыймазиева

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары __________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы «Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Нульдән тегү»** - тегүнең база күнекмәләрен үзләштерүгә, гади эшләнмәләрне мөстәкыйль әзерләүгә, Киемнәрне конструкцияләү һәм бизәү принципларын аңлауга, иҗади потенциалны үстерүгә һәм киләчәктә һөнәри үсешкә әзер булуга юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 11 яшьтән алып 12 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 56,3 кв.м., балалар саны - 7.

ТР Тукай муниципаль районы
«Биклән урта гомуми белем бирү мәктәбе»
МБГББУ директоры ____________ З. А. Гыймазиева